ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/16

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1.Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/6 санлы Карары белән расланган Шәһәр Советы Регламентына (Шәһәр Советының 2014 елның 5 мартындагы 29/18, 2014 елның 10 июлендәге 31/22 санлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 маддәнең 3 өлешендәге 21-32 абзацларны көчен югалткан дип санарга;

2) 16 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Шәһәр Советы депутатлары Шәһәр Советы тарафыннан карала торган мәсьәләләр буенча уртак эшчәнлек алып бару өчен фракция яисә төркем рәвешендә депутат берләшмәләре оештыра алалар.

2. Фракция Шәһәр Советында депутат мандатларын бүлүгә кертелгән сәяси партияләр тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутатлар берләшмәсе булып тора. Фракциягә кандидатларның тиешле исемлеге составында сайланган барлык депутатлар, саннарына бәйсез рәвештә, керә. Фракциягә шулай ук бер мандатлы округлар буенча сайланган депутатлар һәм федераль закон нигезендә үз эшчәнлеген туктаткан сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар да керә ала.

3. Фракциянең тулы исеме – кандидатларның исемлеге составыннан сайланган депутатлар кергән сәяси партиянең уставында күрсәтелгән исем. Фракция шулай ук фракция турында нигезләмәдә

билгеләнгән тулы исеменә туры килә торган кыскартылган исемгә ия булырга хокуклы.

4. Сәяси партия эшчәнлеге туктатылган очракта, аның Шәһәр Советында фракциясе эшчәнлеге, шулай ук депутатларның әлеге фракциядәге әгъзалыгы юридик затларның бердәм дәүләт реестрына тиешле язма кертелгән көннән туктатыла. 5. Әлеге маддәнең 2 өлеше нигезендә, сәяси партия тарафыннан күрсәтелгән кандидатлар исемлеге составында сайланган депутат үзе кергән фракциядән чыгарга хокуклы түгел. Күрсәтелгән депутат кандидатлар исемлеге составында үзе сайланган сәяси партиянең генә әгъзасы була ала.

6. Бер мандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә керә торган депутат яисә, әлеге маддәнең 4 өлешендә күрсәтелгәнчә, сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган депутат фракциягә керә торган сәяси партиянең генә әгъзасы була ала.

7. Әлеге маддәнең 4 өлешендә күрсәтелгәнчә сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган һәм Шәһәр Советында үз фракциясе булган сәяси партиягә кергән депутат әлеге фракциягә керә һәм аннан чыгарга хокуклы түгел.

8. Бер мандатлы сайлау округы буенча сайланган һәм фракциягә кергән депутат фракциядән хәбәр итү тәртибендә чыгарга хокуклы.

Депутатның фракциядә әгъзалык итүен туктату турындагы мәгълүмат ул әгъза булуын туктатканнан соң уздырылучы беренче Шәһәр Советы утырышында игълан ителә.

9. Әлеге маддәнең 5-7 өлешләрендә каралган таләпләрне үтәмәү депутат вәкаләтләрен туктатуга китерә.

10. Кандидатлар исемлеге составында сайланган Шәһәр Советы депутатлары фракциясенә керүче депутатның (депутатларның) вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату сәбәпле, фракциядә депутат (депутатлар) калмаган очракта, мондый исемлек составында сайланган депутатлар (депутат) булмау сәбәпле, Шәһәр Советында күрсәтелгән фракция эшчәнлеге туктатыла. Бер үк вакытта. фракция составына кергән, бер мандатлы сайлау округлары буенча сайланган депутатларның һәм, әлеге маддәнең 4 өлешендә күрсәтелгәнчә, сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатларның мондый фракциядә әгъза булып торуы туктатыла.

11. Фракция эшчәнлеген туктату турындагы мәгълүмат, әлеге маддәнең 4, 10 өлешләре нигезендә, Шәһәр Советының фракция эшчәнлеге туктатылганнан соң уздырылучы беренче утырышында игълан ителә.

12. Бер мандатлы сайлау округлары буенча сайланган һәм фракцияләргә кермәгән депутатлар, әлеге маддә нең 4 өлешендә күрсәтелгәнчә, сәяси партия кандидатлары исемлеге составында сайланган депутатлар, кимендә өч депутаттан торган депутат

төркемнәрен төзергә мөмкин. Күрсәтелгән депутат төркемнәре территориаль, һөнәри яисә башка билгеләр буенча формалаша.

13. Депутат бары тик бер депутат берләшмәсендә генә торырга хокуклы.

14. Фракцияләр һәм депутатлар төркемнәре тигез хокукларга ия.»;

3) 32 маддәнең 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Шәһәр Советының утырышлар залында әлеге Регламентның 103 маддәсенең 4 пунктында күрсәтелгән затлар өчен махсус урыннар билгеләнә. Шәһәр Советы утырышын уздыру залында урыннар булмаган очракта, шулай ук күрсәтелгән затлар утырышка соңга калган очракта, әлеге затлар утырыш залыннан турыдан-туры трансляция гамәлгә ашырылучы башка урынга җибәрелә,»;

4) 35 маддәнең икенче абзацында:

- 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше стратегиясен раслау;»;

- түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктны өстәргә :

«11) шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау.»;

5) 45 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр Советы карарлары Шәһәр Советы карары белән билгеләнгән рәсми бастырып чыгару чыганакларында басылып чыга, шәһәрнең рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (pravo.tatarstan.ru) урнаштырыла.»;

6) 46 маддәнең икенче абзацын көчен югалткан дип санарга;

7) 69 маддәнең 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча белән тулыландырырга:

«5) чагыштыру таблицасы (Шәһәр Советы Карарына үзгәрешләр кертү турында проект кертелгән очракта).»;

8) 78 маддәнең 1 өлешен көчен югалткан дип танырга;

9) 87маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Контроль-хисап палатасы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторлары Шәһәр Советы тарафыннан, ачык тавыш бирү нигезендә, Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелек тавыш белән билгеләнә.

2.Контроль-хисап палатасы рәисе вазыйфасына кандидатуралар турында тәкъдимнәр Шәһәр Советына кертелә:

1) шәһәр Хакиме тарафыннан;

2) Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән бер өлеше санындагы Шәһәр Советы депутатлары тарафыннан.

3. Контроль-хисап палатасы рәисе һәм аудиторлары вазыйфаларына кандидатураларны алдан карау Шәһәр Советының профильле даими комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

10) 103 маддәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) Шәһәр Советы утырышларында гражданнар (физик затлар), шул исәптән оешмалар (юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре булу.»;

11) 106 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәһәр Советы Регламенты нигезләмәләрен аңлатуны профильле комиссия башкара.

Шәһәр Советы Регламентының үтәлешен шәһәр Хакиме, муниципаль берәмлек Башлыгы Урынбасары һәм Шәһәр Советы Президиумы контрольдә тота.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев